Манзарас авыл җирлеге Советы

КАРАР

25.05.2020 ел №10

Манзарас авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 маендагы 22 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен сайлау округлары схемасын төгәлләштерү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25 статьясы нигезендә, Манзарас авыл җирлеге территориясенең алга таба үсеше, яңа урамнар барлыкка килү һәм яңа йортларны кулланылышка кертү сәбәпле, округларның расланган чикләре кысаларында бермандатлы сайлау округларының гамәлдәге схемасын төгәлләштерү максатыннан, Манзарас авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын төгәлләштерергә (Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 маендагы 22 номерлы карарына кушымта), түбәндәгеләрне кертеп:

1.1. 2 нче номерлы Школьный бермандатлы сайлау округына: Энергетиклар урамы, Полевая урамы, Васильковая урамы, Чишмәле урамы, Радужная урамы, ТАССРның 90 еллыгы урамы, Мирсәй Әмир урамы, Ибраһим Газизуллин урамы, Валентин Кельмаков урамы, Надежда урамы, Халыклар дуслыгы урамы, Горная урамы, Цветочная урамы, Вишневая урамы, Ягодная урамы, Рим Зарипов урамы, Әхмәт Фәтхуллин урамы, Б. Хисаметдин урамы;

2. Әлеге карарны «Хезмәт даны» газетасында, Манзарас авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (www. kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Хәбибуллина